**ГЛАВА ИСКЕ-КАЗАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422730, Республика Татарстан, Высокогорский район,, с.Куркачи , ул. Клубная , 4

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ-КАЗАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**
422730, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Коркачык авылы, Клуб ур.,4

Тел./факс: +7(84365) 70-700, e-mail:.Ikaz.Vsg@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«02» ноябрь, 2021 ел** **№3**

**Биектау муниципаль районы Иске Казан авыл җирлегенең Камай авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләләре буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Биектау муниципаль районы Иске Казан авыл җирлеге Уставының 22 статьясы һәм 2019 елның 21 октябрендәге 167 номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Иске Казан авыл җирлеге составына керә торган торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» карары (19.05.2020 елның 187 номерлы редакциясендә) нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Иске-Казан авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2021 елның 17 ноябрендә 14 сәгатькә Биектау муниципаль районы Иске-Казан авыл җирлегенең Камай авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге сорауны расларга:

2021 елда яшәү урыны буенча теркәлгән һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Иске-Казан авыл җирлегенең Камай авылы территориясендә даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне: вак таш сатып алу һәм Камай ав. посёлок эчендәге юлларына вак таш җәю,
үтәүгә юллау белән килешәсезме?

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

5. Әлеге карарны кабул ителгән көненнән алып 3 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм җирлекнең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Иске-Казан авыл җирлеге
башлыгы Г.Р. Закирова